**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“19” ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкарырга:

1) Яңа Әтнә авылы урамнары юлларын төзекләндерү (таш белән каплау эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү);
2) Урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру һәм ремонт өчен материаллар сатып алу);

«РИЗА» «КАРШЫ»

«2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән Яңа Әтнә авылы Яшьләр урамы юлына асфальт җәю чен 50000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) Яңа Әтнә авылы Совет, Яшьләр, Садовая,Новая һәм Дуслык урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү һәм каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чүп-чарны чистарту);

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

**Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:**
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 229 (ике йөз егерме тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 147 (йөз корык җиде) кеше, 64,1,0%.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы116 (йөз ун алты) кеше тавыш бирде, 78,9%;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 31( утыз бер) кеше тавыш бирде, 21,1%.

**Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – **дөрес дип танырга**.

2. Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Яңа Әтнә авылы урамнары юлларын төзекләндерү (таш белән каплау эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү);

2) Урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру һәм ремонт өчен материаллар сатып алу);

3. 2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән Яңа Әтнә авылы Яшьләр урамы юлына асфальт җәю чен 50000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) Яңа Әтнә авылы Совет, Яшьләр, Садовая,Новая һәм Дуслык урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү һәм каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чүп-чарны чистарту)

- **мәсьәләсен кабул итәргә.**

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.